**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасында Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе төзелүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында кушымтада бирелүче нигезләмәне расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 01 февраль
№ ПУ-48

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның « 01 » февралендәге
ПУ- 48 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Президентының**
**Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында**
**нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе (алга таба – Идарә) Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының структур бүлекчәсе булып тора, турыдан-туры Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә буйсына. Идарә эшчәнлегенә вазыйфаи бурычлары нигезендә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары күзәтчелек итә.

2. Идарә үзенең эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе боерыклары нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып тормышка ашыра.

3. Идарә турында нигезләмә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

II. Идарәнең төп бурычлары

4. Идарәнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасы мәгълүмат сәясәте һәм мәгълүмати куркынычсызлык мәсьәләләре буенча массакүләм коммуникация өлкәсендә тәкъдимнәр әзерләү, мәгълүмати көн тәртибен һәм Татарстан Республикасы мәгълүмати мәйданын булдыруда һәм координацияләүдә катнашу, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты кушуы буенча әлеге тәкъдимнәрне гамәлгә ашыруда катнашу;

мәгълүмати мәйданда Татарстан Республикасын һәм Татарстан Республикасы Президентын таныту эшен фаразлау һәм аның белән бәйле көтелмәгән хәлләрне ачыклау;

Татарстан Республикасы Президентына тиешле докладлар әзерләү максатларында Татарстан Республикасында сәяси процесслар барышы, республиканың социаль-икътисадый үсеше, тышкы элемтәләре, булачак зур чаралар ягыннан чыгып караганда, мәгълүмати мәйданны мониторинглау, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларындагы басмаларны мониторинглау;

массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен мәгълүмати көн тәртибенең аеруча актуаль мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты позициясен җиткерү брифинглары оештыруда һәм уздыруда катнашу;

вакыйгалар буенча мәгълүмат җиткерүне планлаштыру;

иҗтимагый-сәяси чаралар һәм вазгыятьне, шул исәптән протест белдерү рәвешендәгеләрен дә, мәгълүмати яктыртуны координацияләү;

мәгълүмати мәйданда Татарстан Республикасының уңай йөзен формалаштыруга юнәлтелгән проектларны координацияләү.

## III. Идарәнең төп функцияләре

5. Идарәнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

мәгълүмати мәйданны мониторинглау;

үз компетенцияләре вәкаләтле органнар белән бергәләп Татарстан Республикасының мәгълүмати сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыруда чикләрендә катнашу;

Татарстан Республикасы Президентына массакүләм мәгълүмат чараларындагы, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Идарә компетенциясенә караган басмаларга һәм хәбәрләргә күзәтү әзерләү;

социаль әһәмияткә ия булган мәсьәләләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча җәмәгатьчелек фикерен ачыклау өчен мәгълүмат мәйданын өйрәнү;

Татарстан Республикасының мәгълүмат өлкәсендәге сәясәте һәм аның мәгълүмати куркынычсызлыгы өлкәсендә четерекле сораулар һәм аларны хәл итү буенча тәкъдимнәргә кагылышлы аналитика материаллары әзерләү;

Татарстан Республикасы Президентына җәмгыять тормышының сәяси, социаль-икътисадый, дини, мәдәни өлкәләре үсешенә кагылышлы мәгълүмат мәйданының төрле ресурсларында чагылыш тапкан тенденцияләр турында мәгълүмат бирү;

мәгълүмат чараларын һәм мәгълүмат кампанияләрен оештыру;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын эшләтүгә Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча карашларны билгеләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы иҗтимагый үсешенең социаль әһәмияткә ия булган мәсьәләләре буенча контентка мәгълүмати мәйданда этәргеч бирү механизмнарын булдыру һәм камилләштерү мәсьәләләрен күтәрү;

мәгълүмат агымы белән идарә итү проектларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте белән хезмәттәшлектә массакүләм мәгълүмат чаралары аша Татарстан Республикасы Президенты эшчәнлеге турында объектив иҗтимагый фикер тудыру;

Татарстан Республикасы Президенты катнашындагы чараларны, анық әйдәүче профильле белгечләр һәм экспертлар, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм челтәр берлекләре, халыкның төп социаль төркемнәре вәкилләре белән очрашуларын әзерләүдә башлап йөрү һәм аларда катнашу;

Татарстан Республикасы Президентының Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәкаләләре, мөрәҗәгатьләре һәм чыгышлары тезисларын әзерләү;

Татарстан Республикасы Президентының Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча указлары, боерыклары һәм йөкләмәләре проектларын әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыкларын гамәлгә ашыру буенча үз компетенцияләре чикләрендә тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының башка структур бүлекчәләре белән берлектә Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламасы, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының чыгышлары өчен материал җыю, анализлау һәм әзерләү;

Татарстан Республикасы Президентының иҗтимагый әһәмияткә ия булган чараларда, очрашуларда, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының эш сәфәрләре вакытында чыгышлары текстлары һәм тезислары проектларын әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының башка структур бүлекчәләре белән берлектә Татарстан Республикасы өчен актуаль мәсьәләләр буенча массакүләм мәгълүмат чаралары өчен төрле материаллар әзерләү;

Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе йөкләве буенча башка функцияләрне башкару.

## IV. Идарәнең хокуклары

6. Идарә үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы министрлыкларыннан, дәүләт комитетлары һәм ведомстволарыннан, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарыннан,

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар соратырга һәм алырга;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары, шулай ук аларның структур бүлекчәләре белешмәләр мәгълүмат базаларыннан билгеләнгән тәртиптә файдаланырга;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе белән килешү буенча Идарә эшчәнлеге мәсьәләләренә кагылышлы рәвештә тикшеренүләр, конференцияләр, семинарлар, конкурслар, башка гавами акцияләр һәм чаралар уздырырга;

тематик мәгълүмати-белешмә һәм аналитик материаллар, дайджестлар, шул исәптән электрон рәвештә дә, чыгарырга;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының тиешле бүлекчәләре башкара торган финанс, матди-техник һәм башка тәэминаттан билгеләнгән тәртиптә файдаланырга;

Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе каравына Идарә компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләре буенча эшне камилләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәр кертергә.

## V. Идарәнең хезмәттәшлек итүе

7. Идарә үз функцияләрен гамәлгә ашырганда федераль дәүләт хакимияте органнары һәм аларның территориаль органнары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Югары суды, Татарстан Республикасы Арбитраж суды аппаратлары, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, башка оешмалар һәм вазыйфаи затлар белән Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структур бүлекчәләре белән, шул исәптән түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчеләре белән – Татарстан Республикасы Президентына аның йөкләмәләрен үтәү турындагы мәгълүматның вакытлылыгы, тулылыгы һәм объективлыгы мәсьәләләре һәм уртак чаралар уздырганда тиешле докладлар һәм белешмә материаллар бирү буенча;

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты белән – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе эшчәнлеген массакүләм

мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә яктырту мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе белән – Татарстан Республикасы Президенты катнашындагы чараларны; Татарстан Республикасы Президентының сәяси партияләр, иҗтимагый һәм дини оешмалар вәкилләре, социаль-мәдәни өлкә эшлеклеләре, дини берләшмәләр вәкилләре белән очрашуларын, Татарстан Республикасы иҗтимагый үсешенең социаль әһәмияткә ия булган мәсьәләләре буенча контентка мәгълүмати мәйданда этәргеч бирү чараларын планлаштыру өлкәсендә, шулай ук Идарә компетенциясендә булган башка мәсьәләләр буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе белән – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе белән Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм боерыкларын әзерләгәндә;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе белән – Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Президенты катнашындагы чаралар оештырганда;

Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты белән – Татарстан Республикасы Президентының чит илләргә һәм Россия Федерациясе субъектларына визитлары, шулай ук чит ил делегацияләренең Татарстан Республикасына визитлары йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президентының позициясен массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә җиткерү өчен брифинглар уздыруга материаллар әзерләү өлешендә;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты белән – дәүләт граждан хезмәте, кадрлар сайлап алу, Идарә хезмәткәрләренең һөнәри үсеше мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе белән – документлар әйләнеше, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең йөкләмәләрен үтәүгә контроль мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсе белән – Идарә хезмәткәрләре өчен тиешле эш шартлары булдыру, аларга медицина һәм матди-техник хезмәт күрсәтү буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты белән – Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләргә кагылышлы мәгълүмат-аналитик материаллар әзерләү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте белән – Идарә тарафыннан әзерләнгән материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм тарату мәсьәләләре буенча.

## VI. Җаваплылык

8. Идарә хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе раслаган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхсән җаваплы була.

## VII. Идарә эшчәнлеген оештыру

9. Идарәнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

10. Идарә эшчәнлегенә җитәкчелекне Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты Указы белән вазыйфага билгеләп куелучы һәм вазыйфадан азат ителүче җитәкче гамәлгә ашыра.

11. Идарә җитәкчесе:

Идарә эшен оештыра;

Идарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә карауга Идарә структурасы, штат саны, Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү, вазыйфадан азат итү, бер урыннан икенчесенә күчерү, бүләкләү һәм аларны дисциплинар җәзага тарту турында тәкъдимнәр кертә;

Идарә хезмәткәрләренә биремнәрне бүлә;

Идарәнең төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

Идарәгә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

12. Идарә җитәкчесе вакытлыча булмаганда, аның вазыйфаларын урынбасары яисә идарәнең башка вәкаләтле заты башкара.

13. Идарә башлыгы урынбасары һәм Идарәнең башка хезмәткәрләре Идарә башлыгы тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

14. Идарә хезмәткәрләре эшчәнлеге Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан расланган регламентлар нигезендә алып барыла.

15. Идарәнең эшчәнлеген мәгълүмат, документлар, матди-техник яктан, транспорт белән тәэмин итүне, шулай ук аның хезмәткәрләренә социаль-көнкүреш һәм медицина хезмәте күрсәтүне Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының тиешле бүлекчәләре башкара.

___